**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ
И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ
РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан шәһәре **БОЕРЫК**

16.12.2019 1372-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының аерым боерыкларын көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының:

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының чик дәрәҗәдә мөмкин булган ташландыкларны, вакытлыча килештерелгән калдыкларны билгеләү һәм атмосфера һавасына стационар чыганаклардан зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларына рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 8 маендагы 444-п номерлы;

«Калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 23 маендагы 450-п номерлы;

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2016 елның 23 маендагы 450-п номерлы боерыгы белән расланган Калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 1 мартындагы 246-п номерлы;

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2016 елның 23 маендагы 450-п номерлы боерыгы белән расланган Калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 11 апрелендәге 348-п номерлы боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (М.М.Шәехов) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары А.М.Шиһаповны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр А.В.Шадриков